РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района
423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ
423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 48 2019 елның 25 июле

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән муниципаль милкен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен раслау турында» 2016 елның 20 октябрендәге 54 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Аренда шартларында муниципаль милекне нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен муниципаль милек исемлегенә кертелгән муниципаль милкен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү Тәртибен раслау турында» 2016 елның 20 октябрендәге 54 нче номерлы карарына (алга таба – «карар») түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

карарны түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1 Әлеге карарның 1 пунктында каралган тәртиптә муниципаль милекне арендага бирү мөмкинлеген билгеләү өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлеген расларга (кушымта)»

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р. Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 25 июлендәге
48 номерлы карарына
кушымта

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле эшчәнлек төрләре исемлеге

| ОКВЭД коды | Эшчәнлек төре исемнәре |
|---|---|
| 01.11 | Башка төркемләүгә кертелмәгән бөртекле, техник һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү |
| 01.21 | Мөгезле эре терлек үрчетү |
| 01.23 | Дуңгызлар үрчетү |
| 01.61 | Үсемлекчелек һәм терлекчелек өлкәсендә, ветеринария хезмәтләреннән тыш, хезмәт күрсәтү |
| 03 | Балыкчылык һәм балык үрчетү |
| 10 | Азык-төлек продуктлары җитештерү |
| 15.12.1 | Авыл хуҗалыгы кош-корты һәм куян ите җитештерү |
| 10.13 | Иттән һәм кош итеннән азык-төлек җитештерү |
| 10.3 | Бәрәңге, җиләк-җимеш һәм яшелчә эшкәртү һәм консервлау |
| 10.4 | Үсемлек һәм хайваннар майлары һәм туңмайлар җитештерү |
| 10.5 | Сөт продуктлары җитештерү |
| 10.61 | Он-ярма сәнәгате продуктлары, крахмал һәм крахмал продуктлары җитештерү |
| 10.9 | Терлекләр өчен әзер азык җитештерү |
| 10.8 | Башка азык-төлек продуктларын җитештерү |
| 01.49.11 | Бал юнәлешендәге умартачылык |
| 14 | Кием җитештерү |
| 20 | Агач эшкәртү һәм агач эшләнмәләр һәм бөкеләр җитештерү, җиһаздан тыш |
| 85 | Мәгариф |
| 86 | Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү |
| 92 ( 92.71 тыш) | Ял һәм күңел ачу, мәдәният һәм спортны оештыру буенча эшчәнлек |
| 68.32.1 | Бүләкләү өчен яки килешү нигезендә күчемсез милек белән идарә итү |

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р. Долотказина